**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ**

# К А Р А Р

"05" февраль 2019 ел № 49/3

" Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 19 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы ,«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында «Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 13 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы» нигезендә Тукай муниципаль берәмлеге Мәләкәс авыл җирлеге Советы,

Карар:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советының 2017 елның 17 ноябрендә 33/1 номерлы кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Положениене раслау турында " гы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт үтүгә кагылышлы норматив-хокукый актларын әлеге Нигезләмәгә туры китерергә.

4. Мәләкәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны халыкка игълан итәргә.

5. Тукай муниципаль районының рәсми сайтында http://tukay.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы

Совет Рәисе В.И.Артемьев